ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**_28.09.2017_____________**

г.Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ _2480________**

Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык урамы, 7 йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын тартып алу турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак, Җир кодекслары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык урамы, 7 йорт адресы буенча, авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле Серафимович урамындагы 7 нче күп фатирлы торак йорт урнашкан җир кишәрлеген, шулай ук кушымтадагы исемлек (кушымта) буенча күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын (торак һәм торак булмаган биналарны) тартып алырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

-тартып алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләренә;

-күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;

- «Торак сәясәте департаменты» МКУ.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ раслауны тәэмин итәргә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 декабрендәге 3635 номерлы карары, объектның кадастр (яки шартлы) номеры 16:49:010206:166 булган, Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык урамы, 7 нче йорт, 7 нче фатирын алу өлешендә, үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 28 сентябрендәге
2480 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск шәһәре, Кызыл тыкрык урамы, 7 нче күпфатирлы торак йортта урнашкан, авария хәлендә дип танылган һәм сүтелелергә тиешле тартып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары (торак, торак булмаган биналар) исемлеге.

| № кв. | Объектның кадрлар (яисә) шартлы номеры |
|---|---|
| 7 | 16:49:010716:54 |